КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 август г.Казань № 681

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары беләр расланган «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2016 ел, 5 май, 283 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 ноябрь, 875 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 886 нчы, 2019 ел, 7 сентябрь, 799 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 5 май, 283 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 август, 681 нче
карары редакциясендә)

# «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы уставы

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешма (алга таба – Автоном оешма) халыкара, бөтенроссия, төбәкара һәм республика чараларын оештыру һәм үткәрүне, Татарстан Республикасының инвестицияләрне җәлеп итү өлкәсендә конгресс-күргәзмә эшчәнлеген оештыруны, шулай ук Татарстан Республикасын һәм аның мөмкинлекләрен Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә эшлекле туризм базарында таныту һәм Татарстан Республикасына эре конгресс-күргәзмә, эшлекле төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара чараларны җәлеп итүне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешма булып тора.

Татарстан Республикасы Автоном оешманы гамәлгә куючы булып тора.

Автоном оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен һәм вазыйфаларын Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы башкара.

1.2. Автоном оешманың тулы исеме – «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;

Автоном оешманың кыскартылган исеме – «Халыкара программалар дирекциясе» АКБО.

1.3. Автоном оешма Россия Федерациясе территориясендәге һәм аның территориясеннән читтәге банкларда билгеләнгән тәртиптә хисап, валюта счетлары һәм башка счетлар ачырга хокуклы.

1.4.Автоном оешма урнашкан урын – Казан шәһәре, Татарстан Республикасы.

1.5. Автоном оешма законнар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган вакыттан башлап юридик зат буларак төзелгән санала.

1.6. Автоном оешма эшчәнлек вакыты чикләнмәгән рәвештә төзелә.

1.7. Автоном оешма гомуми юрисдикция судларында, арбитраж һәм третейский судларда дәгъвачы һәм җавапчы була ала, Автоном оешма уставында күздә тотылган Автоном оешма эшчәнлегенең максаты нигезендә үз исеменнән мөлкәти һәм мөлкәт булмаган хокуклар ала һәм гамәлгә ашыра ала һәм әлеге эшчәнлеккә бәйле йөкләмәләр башкара.

1.8. Автоном оешма мөстәкыйль балanска, тулы исеме язылган түгәрәк мөһергә, үз исеме булган штамплар һәм бланкларга ия.

1.9. Автоном оешма гамәлгә куючысы йөкләмәләре буенча җавап тотмый. Автоном оешманы гамәлгә куючы автоном оешма йөкләмәләре буенча җавап бирми.

## II. Автоном оешма эшчәнлегенең максаты, предметы, төрләре. Автоном оешма хокуклары һәм бурычлары

2.1. Инвестицияләр җәлеп итү өлкәсендә халыкара, бөтенроссия, төбәкара һәм республика чараларын үткәрүне оештыру, Татарстан Республикасының конгресс-күргәзмә эшчәнлеген оештыру, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә дә эшлекле туризм базарында Татарстан Республикасын һәм аның мөмкинлекләрен алга этәрү һәм Татарстан Республикасына эре конгресс-күргәзмә һәм эшлекле төбәкара,бөтенроссия һәм халыкара чараларны җәлеп итү Автоном оешманы төзү максаты булып тора. .

2.2. Автоном оешма эшчәнлегенең предметы булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп ителеше турында мәгълүмат тарату;

Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп ителеше өлкәсендә норматив хокукый актлар, регламентлар, уку-укыту-методик һәм публицистик материаллар эшләүдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү чаралары үткәрү.

Татарстан Республикасын һәм аның мөмкинлекләрен эшлекле туризм базарында таныту буенча чаралар үткәрү;

Татарстан Республикасына эре конгресс-күргәзмә һәм эшлекле төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара чараларны җәлеп итү.

2.3. Автоном коммерциячел булмаган оешма Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган эшчәнлек төрләрен һәм әлеге Уставта каралган эшчәнлек максатларын гамәлгә ашыра ала, аерым алганда:

халыкара, бөтенроссия, төбәкара һәм республика чараларын, шул исәптән социаль юнәлешле чараларны һәм проектларны оештыру һәм үткәрүне;

массакүләм мәгълүмат чаралары аша, материалларны максатчан тарату, презентацияләр, конгресслар, саммитлар, «түгәрәк өстәл» утырышлары һ.б. үткәрү юлы белән Татарстан Республикасының инвестицион җәлеп ителеше турында мәгълүмат әзерләү, чыгарту һәм таратуны;

инвестицияләр өлкәсендә квалификацияне күтәрү буенча семинарлар, тренинглар, форумнар һәм башка чаралар үткәрүне;

реклама эшчәнлеген;

устав максатларына ирешү өчен кирәкле башка эшчәнлек төрләрен.

2.4. Аларны үтәү өчен махсус рөхсәтнамәләр (лицензияләр) таләп иткән аерым эшчәнлек төрләре Автоном оешма тарафыннан тиешле рөхсәтнамәләрне (лицензияләрне) алу шарты белән генә гамәлгә ашырыла ала.

2.5. Автоном оешма үзе төзелгән максатларга ирешү өчен кирәкле һәм әлеге максатларга туры килә торган эшмәкәрлек эшчәнлеге белән, эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен хуҗалык җәмгыятьләрен булдырып яисә аларда катнашып шөгыльләнергә хокуклы.

2.6. Әлеге Уставта күздә тотылган максатларга ирешү өчен Автоном оешма түбәндәгеләргә хокуклы:

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен хуҗалык җәмгыятьләре төзергә яки әлеге җәмгыятьләрдә катнашырга;

башка коммерциягә карамаган оешмалар төзергә һәм ассоциацияләргә һәм берлекләргә керергә;

билгеләнгән тәртиптә халыкара хезмәттәшлекне тормышка ашырырга, шул исәптән халыкара программаларда һәм килешүләрдә катнашырга.

2.7. Автоном оешма түбәндәгеләргә бурычлы:

Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм башка затларга үзенең эшчәнлеге турында мәгълүмат кертергә;

Автоном оешманы гамәлгә куючыга, Идарәгә әлеге Уставның 5.4 нче пунктында күрсәтелгән документлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итәргә;

коммерция, хезмәт серен һәм законнар нигезендә саклана торган серне тәшкил иткән мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә саклауны тәэмин итәргә.

## III. Автоном оешманың идарә органнары

3.1. Автоном оешманың идарә органнары булып түбәндәгеләр тора:

гамәлгә куючы;

югары коллегиаль идарә органы – Идарә;

бердәнбер башкарма орган – генераль директор.

3.2. Гамәлгә куючы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Автоном оешма уставын әзерләү һәм аңа үзгәрешләр кертү;

Идарә әгъзаларын билгеләү;

генераль директорны билгеләү.

3.3. Идарә биш кешедән тора: дүрт әгъзасы һәм Идарә рәисе. Идарә составында Автоном оешма хезмәткәрләренең өчтән бер өлешеннән дә күбрәк кеше була алмый. Идарә биш еллык вакытка билгеләнә.

Идарә рәисе Автоном оешманы гамәлгә куючы тарафыннан раслана. Идарә рәисе Идарә утырышларында рәислек итә һәм Идарә утырышы беркетмәсен имзалый.

3.4. Идарәнең төп вазыйфасы – оешма алар мәнфәгатьләрендә төзелгән максатларны Автоном оешма тарафыннан саклауны тәэмин итү.

3.5. Идарәнең аерым компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү керә:

1) Автоном оешма эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен, аның мөлкәтен формалаштыру һәм файдалану принципларын билгеләү;

2) Автоном оешма Уставын үзгәртү;

3) Автоном оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар, әгъзалары) составына кабул итү һәм аны гамәлгә куючылар (катнашучылар, әгъзалар) составыннан төшереп калдыру тәртибен билгеләү;

4) Автоном оешма органнарын төзү һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

5) Автоном оешманың еллык хисабын һәм бухгалтерлык (финанс) хисабын раслау;

6) башка юридик затларның Автоном оешмасын төзү, Автоном оешманың башка юридик затларда катнашуы турында, филиаллар төзү турында һәм Автоном оешма вәкиллекләрен ачу турында карарлар кабул итү;

7) Автоном оешманы үзгәртеп кору һәм бетерү турында, ликвидация комиссиясен (ликвидатор) билгеләү турында һәм ликвидация балансын раслау турында карарлар кабул итү;

8) аудитор оешмасын яки Автоном оешманың индивидуаль аудиторын раслау;

9) Автоном оешманың локаль норматив хокукый актларын раслау.

3.6. Идарә кирәк булган саен, ләкин кимендә елга ике тапкыр җыела.

Идарә Рәисе яисә генераль директор Идарә чакырылышын башлап җибәрүче булып тора. Идарә утырышының көн тәртибе кысаларында карап тикшерү өчен мәсьәләләрне Идарә рәисе билгели, шулай ук Идарә әгъзалары яки генераль директор башлангычы буенча көн тәртибенә тәкъдимнәр кертелергә мөмкин.

3.7. Автоном оешма Идарәсенең утырышы, әгәр анда Идарә әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы була.

3.8. Идарә карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы Идарә әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Әлеге Уставның 3.5 пунктының 1-4, 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча идарә карарлары бертавыштан кабул ителә.

## IV. Автоном оешма генераль директоры

4.1. Генераль директор Автоном оешманы гамәлгә куючы итеп билгеләнә. Генераль директорның вәкаләтләре вакыты өч ел тәшкил итә. Идарә генераль директор белән Россия Федерациясенең хезмәт законнары нигезендә хезмәт шартнамәсе төзи.

4.2. Генераль директор:

гамәлгә куючыга һәм Идарәгә хисап тота, Автоном оешма эшләренең торышы өчен җавап бирә;

ышанычнамәдән башка Автоном оешма исеменнән эш итә, барлык дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда Автоном оешма мәнфәгатьләрен яклый;

Автоном оешманың гамәлдәге эшчәнлеге мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә һәм боерыклар чыгара;

Идарә раслаган смета чикләрендә Автоном оешма акчасы белән эш итә, шартнамәләр төзи, Автоном оешма исеменнән башка юридик гамәлләр башкара, банкларда счетлар ача һәм яба;

Автоном оешма хезмәткәрләре вазыйфаларына билгели һәм азат итә, штат расписаниесе нигезендә аларның Идарә тарафыннан раслана торган вазыйфаи инструкцияләрен, Автоном оешма хезмәткәрләренә премия бирү турындагы нигезләмәне раслый;

Автоном оешма филиаллары һәм вәкиллекләре эшчәнлеген тикшерүдә тота;

әлеге Уставта каралган эшчәнлек максатларына туры китереп, Автоном оешма акчаларын һәм мөлкәтен файдаланган өчен үз компетенциясе чикләрендә җаваплылык тота;

Идарә утырышларын әзерләүне һәм үткәрүне оештыра;

бухгалтерлык исәбен һәм хисаплылыгын оештыра;

Автоном оешма Идарәсе һәм гамәлгә куючысы компетенциясенә карамаган барлык мәсьәләләрне хәл итә.

## V. Автоном оешма эшчәнлегенә контроль

5.1. Автоном оешма Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык исәбен һәм статистик хисаплылыгын алып бара.

5.2. Автоном оешма салым органнарына, Автоном оешманы гамәлгә куючыга һәм башка затларга Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең эшчәнлеге турында мәгълүмат бирә.

5.3. Автоном оешмада бухгалтерлык исәбен оештыру, аның торышы һәм дөреслеге, тиешле органнарга еллык хисапны һәм башка финанс хисаплылыгын, шулай ук Автоном оешманы гамәлгә куючыга, кредиторларга һәм массакүләм мәгълүмат чараларына кертелә торган Автоном оешма эшчәнлеге хакындагы мәгълүматларны үз вакытында тапшыру өчен генераль директор җавап тота.

5.4. Автоном оешма түбәндәге документларны саклый:

Автоном оешманың уставы, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Уставка кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, Автоном оешма төзү турындагы карар, Автоном оешманы дәүләт теркәвенә алу хакында документ;

Автоном оешманың балансында булган мөлкәткә аның хокукларын раслый торган документлар;

Автоном оешманың эчке документлары (регламентлар, нигезләмәләр);

Автоном оешманың филиалы яки вәкиллеге турында нигезләмә;

еллык хисаплар;

бухгалтерлык исәбе документлары;

бухгалтер хисаплылыгы документлары;

Идарә утырышлары беркетмәләре;

Автоном оешма аудиторы, дәүләт һәм муниципаль финанс контроле органнары бәяләмәләре;

федераль законнарда каралган башка документлар;

Автоном оешманың эчке документлары, Идарә карарлары белән каралган башка документлар.

5.5. Автоном оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерүдә тоту өчен Идарә тарафыннан өч еллык вакытка аудитор билгеләнә.

5.6. Автоном оешма аудиторы компетенциясе бер елга эшчәнлек йомгаклары буенча, шулай ук Автоном оешма Идарәсе карары буенча теләсә кайсы вакытта Автоном оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлегенә тикшерү (ревизия) үткәрүне үз эченә ала.

5.7. Идарә карары белән Автоном оешма аудиторына ул үзенең вазыйфаларын башкарган чорда акчалата түләү бирелә һәм вазыйфаларын үтәүгә бәйле чыгымнары каплана. Әлеге акчалата түләүләр һәм компенсацияләр күләмнәре Идарә карары белән билгеләнә.

## VI. Автоном оешма мөлкәте

6.1. Автоном оешмага аны гамәлгә куючы тарафыннан бирелгән мөлкәт Автоном оешманың милке була.

6.2. Автоном оешманы гамәлгә куючының ул Автоном оешма милкенә биргән мөлкәткә хокуклары сакланмый.

6.3. Автоном оешма милкендә биналар, корылмалар, торак фонды, җиһазлар, инвентарь, сумнарда һәм чит ил валютасында акча, кыйммәтле кәгазьләр һәм башка мөлкәт, шулай ук милектәге яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка хокуктагы җир кишәрлекләре була ала.

6.4. Акчалата һәм башка формалардагы Автоном оешма мөлкәтен формалаштыру чыганаклары булып түбәндәгеләр тора:

гамәлгә куючы тарафыннан даими һәм бер тапкыр бирелә торган кертемнәр;

ирекле мөлкәти кертемнәр һәм иганәләр;

товарлар, эшләр, хезмәтләр реализацияләүдән табыш;

акцияләр, облигацияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр һәм кертемнәр буенча алына торган дивидендлар (керемнәр, процентлар);

Автоном оешма милкеннән алына торган керемнәр;

законнар белән тыелмаган башка керемнәр.

6.5. Гамәлгә куючы тарафыннан даими һәм бер тапкыр бирелә торган кертемнәр тәртибен гамәлгә куючы мөстәкыйль рәвештә билгели.

6.6. Автоном оешма үзенең йөкләмәләре буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелергә мөмкин булган мөлкәте белән җавап тота.

6.7. Автоном оешмага кергән табыш Автоном оешманың идарә органнары арасында бүленергә тиеш түгел.

## VII. Автоном оешманы үзгәртеп кору һәм бетерү

7.1. Автоном оешма Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә үзгәртеп корылырга мөмкин.

7.2. Автоном оешма фондка үзгәртелә ала.

7.3. Автоном оешма Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә ябыла ала.

7.4. Ябу комиссиясен билгеләгән вакыттан башлап аңа Автоном оешма эшләре белән идарә итү вәкаләтләре күчә.

7.5. Автоном оешма ябылганда даими саклауда булган фәнни-тарихи әһәмияткә ия документлар, шулай ук шәхси состав буенча документлар (боерыклар, шәхси эшләр, шәхси счетлар һ.б.) дәүләт архивларына саклауга бирелә. Документларны тапшыру һәм тәртипкә китерү архив органнары таләпләре нигезендә Автоном оешма көчләре белән һәм акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7.6. Автоном оешма ябылганда кредиторлар таләпләрен үтәгәннән калган мөлкәт, әгәр «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм бүтән федераль законнар белән

башкасы билгеләнмәгән булса, ул төзелгәндәге максатларга һәм (яки) хәйрия максатларына җибәрелә.

7.7. Әгәр ябыла торган Автоном оешма мөлкәтеннән әлеге Устав нигезендә файдалану мөмкин булмаса, ул дәүләт кеременә әйләнә.

## VIII. Автоном оешмада мәнфәгатьләр низагын кисәтү һәм җайга салу

8.1. Автоном оешма хезмәткәренең шәхси (турыдан-туры яки читләтеп) кызыксынуы үзенең хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруга йогынты ясаган яки йогынты ясый алган яки Автоном оешма хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм хезмәткәре булып торган Автоном оешманың хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Автоном оешмасы мөлкәтенә һәм (яки) эшлекле репутациясенә зыян салуга китерүгә сәләтле каршылыклар барлыкка килгән яки барлыкка килә алган вәзгыять мәнфәгатьләр низагы дип аңлашыла.

Хезмәт йөкләмәләрен үтәүгә бәйле рәвештә, Автоном оешма хезмәткәре тарафыннан үзе өчен яки аның белән якын туган яки туган булган зат (ата-анасы, хатыны-ире, балалары, абый-энеләре, апа-сеңелләре, шулай ук хатынының һәм иренең абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары, балалары) өчен, шул исәптән хезмәткәр һәм (яки) аның белән якын туган яки туган булган зат мөлкәти, корпоратив яки башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйле булган оешмалар яки гражданнар тарафыннан акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт рәвешендә табышлар, шул исәптән мөлкәти хокуклар, мөлкәти характердагы хезмәтләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яки нинди дә булса файдалар (өстенлекләр) алу мөмкинлеге Автоном оешма хезмәткәренең үзенең хезмәт вазыйфаларын тиешенчә башкаруга йогынты ясаган яки йогынты ясый алган шәхси кызыксынуы дип аңлашыла.

8.2. Автоном оешманың генераль директоры гамәлгә куючыга вазыйфаи йөкләмәләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

8.3. Автоном оешма хезмәткәре Автоном оешманың генераль директорына вазыйфаи йөкләмәләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр низагына китерә торган яки китерә алган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш. Автоном оешманың генераль директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдәге мәгълүматлар исемлеге, бу мәгълүматларга тикшерү үткәрүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәүгә алу тәртибе Автоном оешманың генераль директоры тарафыннан билгеләнә.